894. 342-1
Я
тат. яз

# ӘБӘЙ

АБАЙ

# ШИГЫРЬЛӘР
# һӘМ
# ПОЭМАЛАР

*Мәхмүд Максүд*
*тәрҗемәсе*

ТАТГОСИЗДАТ
МАТУР ӘДӘБИЯТ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1947

स्८८९४५
२६६०५



# КАЗАХ ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК УЛЫ

Казах халкының бөек улы Абай (Ибраһим Конанбаев) 1845 елда Семипалатинск өлкәсендә туа. Аның әтисе Конанбай Тубыкты ыруында старшина булып, каты табигатьле усал идарәче сыйфатында таныла. Абайны да ул үзе шикелле зур түрә итеп тәрбияләргә тели. Ләкин Абай бөтенләй башка юл сайлый. Халыкнын хокуксызлыгы һәм ярлылыгы, идарә башындагыларның һәм шул исәптән үз әтисенең халыкны чиктән тыш җәберләве Абайның йөрәгендә изүчеләргә карата нәфрәт тудыра.

Абай Семипалатинск шәһәрендә бер мәдрәсәдә укый. Шул чагында ул үзлегеннән Көнчыгыш әдәбиятларын өйрәнә башлый. Фирдәүси, Низами, Нәваи һ. б. иҗады һәм Көнчыгыш галимнәренең әсәрләре белән таныша. Соңыннан ул үз заманындагы Көнчыгыш галимнәрен дә өйрәнә. Татар халкының атаклы галиме Шиһаб Мәрҗани әсәрләрен дә Абай яхшы белә.

Семипалатинскида Абай сөргендә яшәүче рус политик эшлеклеләре белән, рус интеллигенциясенең алдынгы вәкилләре белән аралаша башлый. Алар Абайга бөек рус халкының чиксез бай культурасын өйрәнү һәм үзләштерү эшендә күп ярдәм күрсәтәләр.

Абай үз халкының яктылыкка, чын бәхеткә бару юлларын җырлау дәрәҗәсенә күтәрелә. Авыр, караңгы тормыштан котылу бөек рус халкы ярдәмендә генә мөмкин булачагын ачык аңлый. Үзенең „Гаклия“ дип аталган философик әсәрендә, казах халкына мөрәҗәгать итеп, Абай болай ди:

„Рус фәнен өйрәнү иң кирәкле эш икәнлеген исеңдә тот... Рус телен һәм рус культурасын белергә кирәк. Руслар дөньяны ачык күрәләр. Әгәр син аларның телен белсәң, синең дә дөньяга күзең ачылыр“.

Пушкин, Лермонтов, Крылов әсәрләрен Абай казах теленә тәрҗемә итә.

Даһи рус язучыларының карашларын үзләштереп, Абай да, әдәбиятның, поэзиянең бурычы халыкка хезмәт итү, дип саный.

Абай яшәгән чор—казах халкының авыр кысынкылыкта яшәгән чоры иде, зар заманы иде. Кабилә, ыру башлыклары, дин башлыклары, патша түрәләре казах халкын чиксез изәләр, аны караңгылыкта асрарга омтылалар иде. Абай үз халкының хәсрәтен-моңын җырлады, үз халкы белән бергә әрнеде, бергә сыкранды. Аның җырларында еш кына ялгызлык, зарлану мотивлары ишетелүе бер дә гаҗәп түгел. Ләкин Абай үз халкының бәхете турында уйлый, хезмәтне, табигатьне, чын мәхәббәтне мактап җырлый. Ул ялкынлы мәгърифәтче (просветитель) булып мәйданга чыга, укуга, аң-белемгә өнди. „Гыйлем тапмый мактанма“ ди ул һәм иске мәдрәсәләрнең яраксызлыгын күрсәтә:

Язу яздык,
Хат таныдык,
Дәрес алдык мулладан.
Ул укудан
Нәрсә чыкты,
Һәммәбез дә чи надан.

Абай намуслы хезмәткә, тырышлыкка һәм һәрвакыт халык файдасын күзәтергә өнди.

Хезмәт кылсаң иренми,
Карның туяр теләнми,

ди ул. Кеше көченнән файдаланып, талап, алдап мал җыюга Абай каршы.

Эшләмичә тапкан мал дәүләт түгел,
Нәкъ кар суы шикелле тиз югала.

Икенче бер шигырендә Абай болай ди:

Егет булса, һөнәрле, тырыш булсын,
Яхшылыкка һәр заман хәзер торсын.
Кайбер егет йөридер үзен мактап,
Бер мескен ул, андыйның тамыры корсын.

Хезмәт ияләрен ялкынлы рәвештә сөйгән Абай байларга, ыру башлыклары феодалларга, түрәләргә карата үзенең йөрәгендә шундый ук ялкынлы нәфрәт тойгылары асрый һәм шул тойгыларны бик күп шигырьләрендә зур бер осталык белән чагылдыра. Волость башлыгы турында болай ди ул:

Карны бик тук,
Кадре һич юк,
Карамый үз халкына.
Сүзгә күнми,
Эшли белми,
Ил таларга ашкына.

Ярлылардан көлеп, малы белән мактанып йөрүче бай кешегә Абай менә нинди характеристика бирә:

Мал җыя ул, көчемне белдерәм, ди,
Күзгә төртеп мал белән көйдерәм, ди,
Үзе чучка, бүтәнне эт дип уйлый,
Шулпа биреп, ит биреп сөйдерәм, ди.

Табигать турында язган чагында да Абай хезмәт ияләренең авыр тормышын истән чыгармый.

Үзенең яңа, кыю фикерләре белән генә түгел, бәлки шигырь төзелеше ягыннан да, Абай казах халкының поэзиясендә борылыш ясый. Аның бу хезмәтендә дә рус әдәбиятын, аеруча Пушкинны, Лермонтовны өйрәнүенең матур йогынтысы чагыла. Абай әсәрләренең академик басмасына язылган сүз башында күрсәтелүенчә, Абайдан элек казах шигырь төзелеше ике генә форманы белә иде: һәр юлы 11 иҗекле булып, 4 юллы строфалардан торган шигырь формасы һәм һәр юлы 7 иҗекле булып, юл исәбе буенча строфаларга бүленмәгән шигырь формасы. Абай шуларны оста файдалану белән беррәттән, шигырь төзелешендә яңадан 11 төрле форма барлыкка китерә.

Абай—композитор да иде. Ул үзенең күп кенә шигырьләре өчен махсус көйләр дә чыгара. Абай үзе исән чакта ук, акыннар аның шигырьләрен яттан беләләр. Шул рәвешчә, Абай шигырьләре, халык җырлары хокукын алып, киң казах даласына тарала.

Шагыйрь, галим һәм җәмәгать эшлеклесе сыйфатында Абай үзенең бөтен көчен үз халкына хезмәт итүгә багышлый. Аның тормышы чиксез авыр шартларда үтә. Власть башындагы кешеләр аны өзлексез эзәрлеклиләр, тирәяктагы гаделсезлекләр аның йөрәген әрнетәләр. Ул, үз халкының бәхетле тормыш белән яши башлавын күрмичә, алтмыш яшендә үлә.

Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә казах халкы да, элекке Россиянең барлык халыклары белән беррәттән, азатлыкка чыкты. СССР халыкларының туганнарча бердәм семьясында казах халкы тигез хокуклы, мактаулы урын алып тора. Ленин—Сталин партиясе җитәкчеле-

гендә, бөек рус халкы ярдәмендә ул коммунистик җәмгыять төзүдә актив катнаша, үзенең формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культурасын алга җибәрә. Электә грамотасыз булган казах халкы совет власте елларында бик күп галимнәр, инженерлар, шагыйрьләр, академиклар җитештерде. Хәзерге көндә казах халкының үзенең Фәннәр Академиясе, фәнни-тикшерену институтлары, вузлары бар. Бөек Ватан сугышында казах халкының тугры уллары һәм кызлары зур батырлыклар күрсәттеләр, алар арасыннан бик күпләр Советлар Союзы Герое исемен алуга ирештеләр.

Үзенең иҗат көчен, бөтен гомерен халык бәхете өчен көрәшкә багышлаган Абайны казах халкы да, киң илебезнең барлык бүтән халыклары да зур хөрмәт белән искә алалар. 1945 елның август аенда Абай туугa йөз ел тулу көне билгеләп үтелде. Рус телендә аның барлык диярлек шигырьләрен һәм поэмаларын үз эченә алган җыентык чыгарылды. Абайның күп кенә әсәрләре башка тугандаш халыкларның телләренә дә тәрҗемә ителде. Шул рәвешчә, Абай, казах шагыйре булу рамкасыннан чыгып, СССР халыкларының культура хәзинәләренә яңа җәүһәрләр өстәде.

Шагыйрьнең лирикасыннан, социаль мотивларга һәм табигатькә багышланган шигырьләреннән иң характерлы байтак әсәрне туплаган бу җыентык татар телендә Абай иҗаты белән таныштыру юлында беренче тәҗрибә булarак тәкъдим ителә.

*Мәхмүд Максуд*

Карлар яуса, бөркетче чыга ауга;
Ярылып ята һәрбер эз яңа карда.
Яхшы ат, тату юлдаш бер ганимәт,
Ятышлы уңай киеп аучыларга.
Ашкына аучы күңле, түзә алмый,
Төлкенең киткән эзен күреп тауда.
Чамалап кая таба эз барганын,
Чөяргә дип кулына бөркет ала.
Канлы күзен як-якка йөртә бөркет,
Башыннан томагасын[1] салдырганда.
„Түбән очсам, котылыр төлке“ дип, ул
Биеккә күтәрелә киң һавада.
Үзенең котылмасын белгәннән соң,
Качып барган төлке дә туктап кала,
Авызын ачып, тешләрен кайрап тора,
Җан ачысы батырлык бирә аңа.
Шундый кызык көрәшне күрер өчен
Аучылар җан-фәрманга чаба алга.
Кырык пычак кайраган төлке явыз,
Бөркет тә ничек сугу җаен таба.
Батыр кошның коралы—сигез сөңге,
Ышанычлы, чамасыз үткер бар да.
Канатлары һаваны выжылдата,
Күктән җиргә кинәттән атылганда.
Икесе дә аяусыз тарткалаша,
Чыккандай ике батыр киң мәйданга.
Берәве җир, берәве күк киеге,
Адәм өчен батыша кызыл канга.
Кар ап-ак, бөркет кара, төлке кызыл,—
Нәкъ шулай — зифа кыз су коенганда,
Кара чәчен күтәреп ике терсәк,
Менә суга ташланам, дип торганда.

---

[1] Томага — бөркетнең күзен каплап башына киертелгән күн каплавыч.

Ап-ак тән, бите кызыл, яп-ялангач, —
Кара чәч кызыл йөзне каплаганда;
Кияү кыю, киленчәк сылу булып,
Охшыйдыр тар түшәктә ятканнарга.
Төлкенең каршы торыр хәле калмый,
Бөркет аны ботарлап ташлаганда.
Кошы да, иясе дә нинди шатлар,
Алтмыш ике хәйләле төлке алганда,
„Насыйп булсын тагын да өч көтү“ дип,
Карт-корылар аучыны мактаганда.
Рәхәт була аудан соң ял иткәндә,
Насбай салып, бер гамьсез шатланганда.
Җиләк чүпләп йөргәндәй, төлке алсаң,
Күтәрелә күңелләр шул заманда.
Күкрәктә бертөрле дә яман уй юк,
Очырганда бөркетне һаваларга.
Һичкемгә зыяны юк, үзем беләм,
Кызык табам, тауларда йөреп ауга.
Йөрәге сизгер, зирәк кешеләргә
Барысы да ачык моның, уйлаганда.
Әгәр син үзең ауны яратмасаң,
Ауда йөреп хәсрәтең таратмасаң,
Аңлашылмас язганым, һәрбер сүзен,
Һәр сурәтен белергә җан атмасаң.
Укысаң моны, аучы булып укы,
Укыма, кош чөюдән тәм тапмасаң.

1882

Ягымлы, ак чырайлы, киң маңгайлы,
Сихерли кара күзе синең җанны,
Неп-нечкә кара кашы сызылып киткән,
Әйтерсең, яңа туган кыйгач айны.
Маңгайдан туры төшкән матур борын,
Алма бит, алсу йөзкәй бәйли телне.
Күренә, авызын ачса, ап-ак теше,
Нур сибеп, ашкындыра яшь күңелне
Сөйләсә, сүзе татлы һәм мәгънәле,
Көлсә бер, гүя былбыл кош сайрады.
*Соклангыч, ак ефәктәй муены бар,*
Кояш та яндырырга базмый аны.
Килешле калак-сөяк, җилкәләр киң,
Түшендә ике алма калкып тора,
Иләмсез озын түгел, кыска түгел,
Нечкә бил, зифа талдай, җилдә сыгыла.
Яшь бала тәне төсле беләге бар,
Бик житез, эшкә уңган бармаклар да.
Күзеңнең нурын алыр, шомырт кара
Ефәк чәчен дулкынлатып таратканда.
Кайсы кыз егетләргә күзен атмас,
Сылуы бу заманның йоклап ятмас,
Кул батмас алмалары үпкә була,
Унсигез, унтугыздан яше арткач.
Аларның кайберенең холыклары
Һичнәрсә күрмәгәндәй кырку була.
Кайберсе, ачык йөзле күренәм, дип,
Урынсыз, мәгънәсезгә көлеп тора.
Электән сылу хәле безгә мәгълүм,
Егетне ил мактаса, кыз ярата,
Кай егет, әрсезләнеп, оялмыйча,
Кул җитмәс нәрсәләргә күзен ата.
Акылны үткерләүдән тәм тапмый ул,
Булмаса, хезмәт кылып мал тапмый ул,
Мәгънәле була алмый андый егет,
Дөньяда файдасызга җир таптый ул

1884

* * *

Картайдык, хәсрәт басты, йокы сирәк,
Ачуың—агу, үзең кемгә кирәк?
Серләшергә кемнәр бар, сүз аңларлык?
Күңелне күтәрергә юк бер зирәк.

Әзәлдән[1] яшь картая, тере үлә,
Үткән гомер әйләнеп кайтмый бер дә.
Йөргән юл, күргән кызык артта кала,
Мәңге дә үзгәрми бер тәңре генә.

Ир кеше акыл жыя, тәнне жиңә,
Һөнәрсез—тик жил куып йөри бирә.
Ояты юк, кулыннан бер эш килми,—
Иренчәк, ни әйтсәләр шуңа күнә.

Намуслы хезмәтне һич яратмыйлар,
Угрылыкны, алдауны әй мактыйлар.
Бозык эшнең зыяны булмый калмас,
Бер ватыла, чүлмәкне мең ватмыйлар.

Һәрбер кеше саулыкны дәүләт белсен,
Акыл тапсын, мал тапсын, гадел йөрсен,
Акылы юк, малы юк, миңгерәү жан—
Тормышында ул нинди рәхәт күрсен?

Наданга киңәш бирмә, колак салмас,
Яхшы сүздән беркайчан гыйбрәт алмас.
Тугры сүзнең кем белер хасиятен,
Акылсыз юкка күнәр, чынга ышанмас.

Бизәкле матур кием—хуп күргәне,
Тик йөреп кызык табу—бар белгәне.
Ак сакалның, акылга бай кешенең
Сүзләреннән ул тинтәк көлә әле.

---

[1] Әзәлдән—борын-борыннан, мәңге шулай.

Акыллы син, кырыкка кылны ярсаң,
Һәрнәрсәгә бәһасен бирә алсаң,
Яхшыны һәм яманны дөрес үлчәп,
Белемне арттыруга күңел салсаң.

Надан адәм тыштан дус, эчтән яна,
Якынының кайгысы шатлык аңа,
Бер-ике юлы уңган кеше күрсә:
„Ходай сөеп яраткан бит“ дип кала.

Ил бозылса шайтанга үрнәк була,
Фәрештә йөрәгенә сагыш тула.
„Үземнең этлегемнән килде“ дими,
Җиңде дип, шайтанны да мактап тора.

Койрык болгап, ары да бире чаба,
Пышылдап, берәр гайбәт сөйләп ала.
Хәрәмләп тормыш төзегән кеше бармы?
Беркөнне һәлак була ул бичара.

Ил эшен башкарырга кулдан килми,
Гаделлекне хәйләгә кем соң тиңли?
Мактанырга яратып булыс[1] була,
Соңыннан хур буласын үзе белми.

1886

---

[1] Булыс—волость башлыгы.

* * *

Ярлы халкым, казахым, вәйран илем,
Керпе мыек авызыңа төшкән синең.
Яхшы белән яманны аермадың,
Бер уртың май, берсе кан булган, димен.
Кайдан гына бозылды шулай төсең,
Якты чырай биргәндә яхшы идең.
Белмичә үз сүзеңнән башка сүзне,
Тел белән урак урып йөри бирдең.
Бозылды уен-көлкең, төнге йокың,
Үз малыңны саклаудан җәфа күрдең.
Тезгенсез син, кызыгып һәр күргәнгә,
Бер шиңеп, бер кәпрәеп, мин дип йөрдең.
Эш башында утыргач түбән җаннар,
Бозылмасмы сыйфаты андый илнең?
Төзәлерсең бер заман, дип әйтә алмыйм,
Үз кулыңнан китмәсә әгәр иркең.
Агай-энең бозылган, холкы яман,
Йөз чөерер юк өчен синнән бер көн.
Берлек юк, бәрәкәт юк, татулык юк,
Байлыкны җилгә чәчеп ник бетердең?
Акылыңа, малыңа иркен юл юк,
Көнчелек, ызгыш-талаш көнен-төнен.
Әгәр бер терелмәсәң шул авырудан,
Һәр җирдә кимсетелеп утәр гомерең.
Кырык кеше бер үрне үтә алмыйсыз,
Кай җиреңнән тапсын, ди, куәт күңелең.
Тыйнаксыз, тезгенсез син, бик куркак син,
Юк-бардан кызык табып, бушка көлдең.
Аңлатырдай кешегә туры килсәң,
Астыртын пыш-пыш сөйләвеңне белдең.

1886

* * *

Егетләр, уен арзан, көлке кыйбәт,
Ике нәрсә — эчке хәл, тышкы сыйфат.
Арзан, ялган көлмичә, чын көләрдәй
Ир табылса, ярыйдыр кылса сохбәт[1].

Кайберәү тыңлар өйдән киткәненчә,
Кайберәү колак салыр җиткәненчә,
Сүз мәгънәсен белердәй кайберәү бар,
Аңлар ул һәрбер сүзне үз хәленчә.

Егет сөйсен—чын-чынлап, әгәр сөйсә,
Сүзендә тора белсен, яныл йөрсә.
Кызыл комач шикелле яшь егетләр
Уңалар, бик аз гына бер дым тисә.

Егет булса, һөнәрле тырыш булсын,
Яхшылыкка һәр заман хәзер торсын.
Кайбер егет йөридер үзен мактап,
Бер мескен ул, андыйның тамры корсын!

Яшьлек көне күңелле, тату үтсен,
Барын бүлеш,— һәммәгә тигез җитсен,
Көнчелексез тату бул чын күңелдән,
Хыянәтчел уйларның эзе бетсен!

Йөрегез һәрбер җирдә бергә-бергә,
Берeңнең сүзен берең яклап сөйлә.
Бер-береңне кадерләп хөрмәт күрсәт,
Риза бул дустың өчен җан бирергә.

Юлдашлык, сохбәттәшлек бер зур эш ул,
Аның кадрен белерлек чын кеше бул.
Яхшы ир белгән серен ятка әйтмәс,
Артыңда көләргә дип эзләмәс юл.

---

[1] Сохбәт кылу—утырдаш булу, сөйләшү, фикер алышу.

Һичкайчан, егетмен дип, итмә уйнаш,
Азгынлыкка бирелсәң, кадрең булмас.
Ир егет сайлап табып, белеп йөрсен,
Эткә охшаш кешенең нәфсе туймас.

Берәүне күрке бар дип яхшы күрмә,
Аны-моны уйламый исреп йөрмә!
Хатын яхшы булмыйдыр күрке белән,
Акылын тикшермичә күңел бирмә!

Азгын ирнең гомере бушка узар,
Тыйнаксызлык тормышның ямен бозар.
Көн дә күргән хатыннан күңеле кайтып,
Әдәпсез хатын-кызга кулын сузар.

Зирәк кыз йөрәгеңне хаттай таныр,
Сизә белер: дөресме суга тамыр,
Яры өчен җанын да фида кылып,
Авырлык килгән чакта итәр сабыр.

Бу чакта тагын шундый хатыннар бар,
Чытлыкланып яшьләрне territoryаздыралар.
„Күркем барда күркемә кем чыдар“ дип,
Кәпрәеп, борын чөеп йөри алар.

Акыл кирәк, эш кирәк, аңлау кирәк,
Бу чагында андыйлар очрый сирәк.
Уйнашчы, тинтәкләрдән ни көтәсең,
Оялыр эш кылмас ир, булса зирәк.

Хатының сине сөйсә, син аны сөй,
Булма бер мәгънә белмәс аңгыра ми.
Ир акыллы, хатыны уңган булып,
Тату торса, рәхәткә чумадыр өй.

Сөйгән ярың салмаса ятка күңел,
Алдыңда балкып торса, гүя бер гөл,
Йөрмәсә һичбер төрле начар уйда,
Тар түшәк—алтын тәхеттән ким түгел.

Хәстәрле дип, маллы дип байдан алма,
Ярлы кызы арзан дип анда барма,
Намусы бар, акылы, ояты бар
Ата-ананың кызыннан гафил калма.

Өеңә берәр дустың килеп керсә,
Күңелле — хатын яхшы чырай бирсә,
Ире сөйгән кешене ул да сөеп,
Хөрмәтләп, яхшы нияте белән йөрсә.

Дустың да үзен тота белсен үзе,
Сөйләсә төпле булсын һәрбер сүзе,
Син аңар муен борып сүз дәшкәндә,
Хатыныңда булмасын аның күзе.

Кайберсе бүген тату, таңда дошман,
Явыз теләк — йөрәктә, яхшы — тыштан.
Хыянәтсез, эчкерсез кешеләр бар,
Аерылма һичкайчан шундый дустан.

Хәзер яшьләр файда дип, мал дип туа,
Тик ятып ансат баемакчы була.
Вак сәүдәгәр шикелле көлке сатып,
Туймый нәфсе, туктамый дөнья куа.

Алыш-биреш итәм, дип тик алдаша,
Юк-бардан җәнҗал ясап, күңел ача,
Отыш уйнап, ялганлап, хәрәмзәләп,
Берсен-берсе дөмбәсләп якалаша.

Бик тату уйный башта бала-чага,
Бер анадан тугандай йөри бар да,
Берсен-берсе кочаклап шау-гөр килә,
Уен бетәр алдыннан сугышып ала.

Бер бала елап барса өйгә табан,
Ата-анасы кычкыра аннан яман.
Татулыгы, уены корсын шунда,
Нәкъ шуларга охшыйдыр безнең заман.

Дус күренеп, үзеңә баз казыр ул,
Андыйларга ышансаң булырсың хур.
Намуслы, инсафлы бер өлкән дус тап,
Үзе зурда кешелек буладыр зур.

Чын сүзне бу заманда кайсы аңлый,
Әйткәнеңә күбесе колак салмый.
Бишне биреп алтыны алыр өчен,
Бурычка акча бирә, сине алдый.

1886

* * *

Гыйлем тапмый мактанма,
Урын тапмый шатланма,
Очынма, канатланма,
Юкка-барга сөенеп.
Биш нәрсәне ачык бел,
Биш нәрсәдән качып йөр,—
Кеше булам, дисәгез,
Рәхәт гомер итүнең
Бар хәстәрен күрсәгез.
Алдау, гайбәт, мактану,
Ирену, юкка мал салу—
Биш дошманың, белсәгез.
Тырышлык, хезмәт, тирән аң,
Шәфкать, канәгать һәр заман—
Биш асыл эш, күнсәгез.
Начарлык күрсәң, нәфрәтле,—
Аннан күңел тыйсагыз.
Яхшылык күрсәң, гыйбрәтле,—
Аны өлге кылсагыз.
Галим түгел мин дигән
Балалыкны куйсагыз.
Тырыш шунар охшарга,
Бер галимне күрсәгез.
„Андый булу кайда!“ дип
Әйтмә, гыйлем сөйсәгез.
Сезгә гыйлем кем бирер,
Янмас борын сүнсәгез.
Дөнья да үзе, мал да үзе,
Гыйлемгә күңел бирсәгез.
Белгәннәрнең сүзенә
Колак салып йөрсәгез.
Акыл белән үлчәгез,
Бер эшкә тап килсәгез.
„Аксакал әйтте, бай әйтте“.
Кем булса булсын, шул әйтте,—
Акыл белән җиңсәгез.
Наданнарга юл куйма,

Хак сүз өчен үлсәгез.
Аять, хәдис имәс бит,
Кафер булдың димәс бит,
Әгәр каршы килсәгез.
Күп әйтә дип син әйтмә,
Безнең сүзгә күнсәгез.
Моны язган кешенең
Исемен белмә, сүзен бел!
Ошбу фани дөньяда
Берәү дә мәңге түгел,—
Менеп йөрсә дә дөлдөл[1].
Сүз мәгънәсен белсәгез,
Акыл бизмәненә сал.
Әгәр кыйшык күренсә,
Читкә ташла, я бер көл;
Әгәр төзек күренсә,
Ансын колагыңа эл.
Акыллы аз, ахмак күп,
Әйтмә: күпнең сүзе шул.
Якынның сүзе яхшы дип,
Якыным әйтте дип йөрмә.
Наданлыктан әйтелгән
Төпсез бер сүзгә күнмә,
Миннән сезгә киңәш шул.
Үзең өчен өйрәнсәң,
Начарлыктан җирәнсәң,
Ачылырсың елдан ел.
Берәү өчен өйрәнсәң,
Берәү белми син белсәң,
Белемеңнең бары — тол[2].
Сүзенә карап кешене ал,
Кешегә карап сүз алма.
Чын сүзне аермыйча,
Һәрнидән коры калма!
Моны язды белгән кол.
Голәмаи Давани[3]
Шулай дигән, бу чындыр.
Укып чыккач, бер уйла,
Тиз өйрәнеп тиз җуйма,
Яшь вакытта зиһен мул.

1886

---

[1] Дөлдөл—дини экиятләрдәге Гали батырның аты, имештер очар коштай тиз йөргән.
[2] Тол белем — бушка киткән белем мәгънәсендә.
[3] Давани исемле галим.

## ҖӘЙ

Җәй көне рәхәт һәр җирдә,
Гөрләп үскән ал гөлләр
Күңелгә шатлык бирә.
Су буена җәйләүгә
Авыллар күчеп килә.
Елкылар да, тайлар да
Ашап йөреп арганда,
Чыдый алмый кызуга,
Суга кереп хәл ала,
Койрык белән кизәнә,
Чебен-черки сарганга.
Яшь колыннар шаярып,
Йөри шунда, арада.
Кыр үрдәге, кыр казы
Оча биек һавада.
Яшь киленнәр, яшь кызлар,
Җиң сызганып ала да,
Елдам йөреп, өй тегә,
Уен-көлке аларда.
Ашыкмый, салмак йөреп,
Мыек астыннан көлеп,
Кайтып килә бай үзе,
Барган ул мал карарга.
Сабадан кымыз койдырып,
Нәкъ уртага куйдырып,
Карт-корылар гәпләшә,
Сүз төкәнми һаман да.
Ялчы аны өйрәткән,—
Сабый бала ит сорый,
Әнисенә бара да.
Күләгә бар башына,
Келәм түши астына,
Кайнап тора самовар
Солтанатлы байларда.

Бәйге атыдай ашкынып,
Белемләләр сүз ала,
Бүтәннәре, хуп күреп,
Башны изи аларга.
Ак күлмәктән, таяктан,
Бабай чыга бер яктан,
Көтүчегә кычкыра:
„Арырак ку, абайла!“
Бай „байгышым!“ дисен, дип,
Чакрып кымыз бирсен, дип,
Тели аңар ярарга.
Иртә таңнан ат менеп,
Малларны карап йөреп,
Елкычылар кайталар,
Кояш баеп барганда.
Мылтык аскан, кош чөйгән
Яшь егетләр бер төркем,
Күңел ача яланда.
Аучыларның бөркете
Кыр казына ташланып,
Биек оча һавада.
Гомерләр узып киткән,
Тәндә инде көч беткән.
Мескен теге ярлы карт
Көлгән була, тырыша
Бай күңелен табарга.

1886

* * *

Шигырь—сүзнең патшасы, сайланмасы,
Килештереп әйтәдер ир данасы.
Телгә җиңел, йөрәккә җылы биреп,
Теп-тигез, матур килеп торсын барсы.

Бүтән сүзгә буталса сүз арасы,
Ул — акынның белемсез бичарасы.
Әйтүче, тыңлаучының надановы күп,
Һич юк аның чын сүзне бер аңласы.

Һәркем дә шигырь әйтеп дан аласы,
Ерак тик — шигырь белән ике арасы.
Эче алтын, тышы көмеш сүз яхшысын
Казахның әйтә белә күп баласы.

Борынгы, иске бигә күзне салам,
Мәкальләп кирәксезне сөйли һаман.
Акыннары акылсыз, надан халык,
Күп вакыт шигырь тезә юктан-бардан.

Кулына кубыз белән домбра ала,
Мактап шигырь әйтергә баига бара,
Һәр җирдә шигырь белән хәер эстәп,
Сүз кадерен китәрә ул дивана.

Мал өчен газиз җанын утка сала,
Алдаша, намусыннан коры кала.
Чит җирдә хәерчелек кылып йөри,
Үз илен бай дип мактый йөзе кара.

Кайда бар мактанчык бай, бара шунда,
Баемый, җыйган белән малны кулга.
Казахта шигырьнең бар кадре бетте,
Шундыйлар тулып яткач уңда-сулда.

Иске бидәй буш мәкаль сөйләп йөрмә,
Мал өчен җыр җырлауда кызык күрмә,
Мәгънәсез сүз сөйләүдән ләззәт тапмыйм,
Төзек сүзгә, тыңлаучым, төзәл син дә.

Байны әйтсәм, күпме мал алган талап,
Кызны әйтсәм, сылу дип, күзгә карап,
Ничә көннәр әңгәмә барыр иде,
Тыңлар идең, бер сүзем меңгә санап.

Тугры сүз әйтеп, кемгә була ярап?
Кирәк иде күрергә бер чамалап.
Бу чагында белемсез тинтәкләр күп,
Үпкәләмә, җибәрсәм нык яманлап.

Теләгән карагайны талга ялгар,
Эзләгән үз бәхетен үзе табар.
Мал сөяр мактанчыкка акыл бирмә,
Аңласа, ничә меңнән берәү аңлар.

Хәрәмләшеп мал җыя, урлый, алдый,
Һәртөрле түбәнлеккә яхшы карый,
Илнең баен тилертә „Яу килә“ дип,
Файдасы булмасмы дип тик ялганлый.

Дөньяда инсаф, оят, гаделлек бар,
Боларның кирәге юк һич тә аңар,
Уйланмас, тирән гыйлем эзләмәс ул,
Ялган белән гаибәтне артык санар.

1887

## КЫШ

Ак киемле, ак чырай, ак сакаллы,
Сукыр, телсез, танымас тере җанны,
Өсте-башы ак кырау, төсе суык,—
Кыш килде, баскан җире сыкрап калды.

Суласа, буран чыга, салкын була,
Карт кода — кыш безгә күп бәла салды.
Болыттан бүрек кигән, кыңгырайтып,
Ачы җилле салкыннан бит алланды.

Каплаган калын кашы ике күзен,
Баш селексә, кар явып мазаң алды.
Карт дөядәй ачулы дулаганда,
Алты почмак өр-яңа өй чайкалды.

Кызык табып йөгергән балаларның
Кулы туңып, битләре уттай янды.
Сары тун, чикмән кигән мал караучы,
Чыдый алмый, җил якка куйды арканы.

Җир туңган, кар тибеп тә үлән чыкмый,
Елкы малы бик авыр хәлгә калды.
Кыш белән бергә явыз бүре килә,
Малчыларым, хур итмә, сакла малны.

Яхшы карап йөртегез, күзәтегез,
Аз йоклап әллә үлгән кеше бармы?
Эткә бирмә, Кондыбай, Канайга[1] бир,
Куып җибәр әнә шул карт ялкауны!

1888

---

[1] Кондыбай, Канай—болынчыкларын байларга сатып яшәгән авыллар.

## СИГЕЗАЯК

Ерактан балкып,
Йөрәктән калкып,
Яндырып тәнгә таралган,
Тауларда чабып,
Теләген табып,
Киеккә барып кадалган,—
Дулкыны туксан, тапкыр тел,
„Сөймимен“ дисәң үзең бел!

Хәнҗәрнең йөзе,
Останың безе
Бизәкне синдәй сала алмас;
Белгәнгә мәрҗән,
Тинтәккә арзан,
Наданнар гыйбрәт ала алмас;
Кыйналма һич тә буш җиргә,
Сантыйга чын сүз — ул нигә?

Башында ми юк,
Үзендә уй юк,
Мактанчык, дорфа наданның;
Күп әйтсә күнә,
Шул шәп, дип белә,—
Гадәте надан адәмнең.
Күңел күзе булмагач,
Сүз сөйләмә, ул—агач!

Кайныйдыр каның,
Әрнидер җаның,
Шундыйларны күргәндә;
„Йоклама, эшлә,
Ләззәт тап эштә!“
Дип нәсихәт биргәндә,
Оятсыз, әрсез тыңлармы,
Торып китәр, бел аны.

Тик үзен белә,
Чиксез зур күрә,
Әйткәнне һич тә аңламый;

Акылы такыр,
Үзенчә — тапкыр.
Бүтәннәр аңа ярамый.
Намуссыз, әрсез бер надан,
Нигә дип туган анадан?

Гайбәт тарату,
Эшне таркату,—
Кызык табып йөргәне;
Макталсын һаман,
Кәпрәйсен яман,—
Уйлаганы, белгәне.
Инсаф, оят берсе юк,
Шуны күрер кеше юк.

Үч саклый белмә,
Тугры бул илгә,
Эшлә, көчне аяма,
Урынсыз көлсәң,
Ваемсыз йөрсәң,
Килерме дәүләт — абайла!
Хезмәт кылсаң иренми,
Карның туяр теләнми.

Игеннең ибен,
Сәүдәнең серен
Өйрәнеп, белеп, мал эзлә;
Адәм бул, мал тап,
Чын сөяр җан тап,
Куаныч, шатлык шул безгә.
Талашса казах һаман да,
Эшебез китәр яманга.

Малыңны яуда,
Башыңны дауда
Бетермә, тыныч, тату бул;
Ялганлау, хурлау,
Җәберләү, урлау
Калмасын, сайла тугры юл!
Оят, инсаф уянсын,
Акылы барлар уйлансын!

Тамагы туклык,
Кайгысы юклык
Аздыра адәм баласын.
Талашып бушка,
Ташланып дуска,

Хур булып, корып барасың.
Алдар чагың үтте бит,
Үкенер вактың җитте бит.

Дөньяны айкап,
Урлашып мал тап,—
Дигән кеше юк сезгә.
Бирәү дә азмас,
Юлыннан язмас,—
Колак салса хак сүзгә.
Күркәм булса гадәтең,
Бер күрерсең рәхәтен.

Авырмый тәнем,
Авырды җаным,
Каңгыртты, изде башымны;
Сыкранды йөрәк,
Кысылды күкрәк,
Агызды күздән яшемне.
Куана алар туклыкка,
Күнгәннәр һөнәр юклыкка.

Бетмәде эшем,
Төкәнде көчем,
Максут ерак, гомер аз;
Базарың үткәч,
Ялкының беткәч,
Тагын бер кат килми яз.
Кире кайтыр юл түгел,
Юл азыгым мул түгел.

Һичбер кемнең дә
Бирәүнең миңгә
Хәле җиткән заман юк.
Кадерле көнем,
Яшьлегем-гөлем
Бушка китте, чарам юк.
Мәгънәсезгә үтте гомрем
Әрни хәзер шуңар күңлем.

Барын да күрә,
Законны белә,
Мактана чиксез һәр җирдә;
Сискәнеп, куркып,
Юргалап, юртып,
Ялынса иле, шул җитә.

Яратканын зур итә,
Ачуланса хур итә.

Курыкты илең,
Үзеңнең синең
Һөнәрең нәрсә—әйтеп бир!
Сөймисең илне,
Ил сөйми сине,
Үтмәсен вакыт—уйга кил!
Сагалап азгын хатынны,
Югалта күрмә оятыңны!

Ачылырмы күзең,
Бер ялгыз үзең,
Уйлан бер, аңла барсын,
Бик якын күргән,
Сереңне белгән
Дус кешең алдамасын.
Ул—пычрак җанлы бер бәндә,
Өстерәр сине түбәнгә.

Баш-күз кан булган,
Кыйнап куылган,
Тагын килә яныңа;
Егылып, торып,
Кулларын кушрып,
Тагын сиңа ялына.
Намус кайда, әр кайда,
Алай йөреп ни файда?

Эт өрсә, бала
Таягын ала,
Куа ул этне үчекләп,
Орышып, „уй!“ дип,
„Оят!“ дип, „куй!“ дип,
Өлкәннәр тора үгетләп.
Аны белсәң, моны аңла,
Үзең дә оятка калма!

Белгәнгә юл киң,
Сызгана да җиң
Һөнәрдән ләззәт аладыр;
Белмәгән күзсез,
Ваемсыз, сүзсез,
Тамагы туйса—авадыр,
Ни ул түгел, бу түгел,
Минем дә көнем көн түгел.

Гыйлемне эзләп,
Дөньяны күзләп,
Төрле якны урадым,
Колагын салмас,
Сүзеңне алмас
Күп наданнан кыйналдым.
Тотынса ике көймәгә,
Котылмак юк кемгә дә.

Кыяга бардым,
Бер аваз салдым,
Яңгырау ерак таралды.
Очрыйм дип дуска,
Бик озак бушка
Эзләндем, хәлем калмады.
Ничә барсаң, бер кыя,
Җансыз кыя—ни тоя?

Җәяүле ятты,
Атлысы чапты,
Акыллы сүзне кем тыңлар?
Йөрәктә—янгын,
Авыздан ялкын,
Мөлдерәп күздән яшь чыгар.
Әрнесә җан, чыдатмый,
Куярмы бер җылатмый?

Мендәрем мамык,
Йокымны алып,
Таш булып бата тәнемә;
Бетмидер сүзе,
Мәст булган үзе,
Күз салмый адәм хәлемә.
Һаман да шул ялганлау,
Антлар эчеп алдалау.

Атадан алтау,
Анадан дүртәү,
Ялгызлык күрер җирем юк,
Якыннар да бар,
Тик сүзне аңлар,
Мәгънәсен табар илем юк.
Багучы карт кабре күк,
Ялгыз калдым—зарым күп.

1889

* * *

Шигырь язмыйм бер кызык курмәк өчен,
Юкны-барны сөйләнеп йөрмәк өчен,
Язамын саф күңелле, тапкыр телле
Яшьләргә матур өлге бирмәк өчен,
Сүз аңламас наданнар өчен түгел,
Күңеленең күзе ачык зирәк өчен.

Турыдан кил, уратып кыйшык килмә.
Тыштан күреп эш бетми,— белдем, димә.
Колак сал, иренмичә, яхшы тыңла,
Мондый сүз ишеткәнең юк ич бер дә.
Халык гаҗәп: әйткәнне аңлап җитми,
„Тагын әйт!“—дип тынгылык бирми нигә?

Хәзрәте Гали юк бу җырларымда [1],
Язмыймын алтын ияк кызларны да,
Карт-корыны яманлап, үлем теләп,
Яшьләргә кушмыйм әрсез кыланырга.
„Сүзләрендә бизәк юк“ дип әйтмәгез,
Төбе тирән, мәгънә бар уйланырга.

Батырдан барымтачы [2] туар, диләр,
Яраксыз кызык табар, ялган сөйләр,
Әрсез, малсыз, акылсыз һәм эшлексез,
Эшләмәс ул дөньяда ниләр-ниләр.
Сөйләүдән тукта, телем, көлеп торса
Биш-алты миңгерәү җан,— куып җибәр.

Җырга оста, һөнәрле энем, син дә,
Ялынамын, очырма сүзне җилгә,
Үзеңә һәм бүтәнгә файдасы юк,
Әрәм итмә һөнәрне булмас җирдә.
Оят качкан, мактанчык уйнашчы ир,
Аңламас бернәрсә дә, акыл бирмә!

1889

---

[1] Абай үзенең бу сүзләрен Мөхәммәт пәйгамбәр яраннарыннан Гали батырны мактап җырлаган Күкбай акынга каратып әйтә.

[2] Барымта—урлап мал алып китәргә бару; кабиләләр арасындагы ызгыш мәгънәсендә дә кулланыла. Барымтачы—барымтада катнашучы.

* * *

Син мине нишләтәсең?
Тыңла, җаным!
Сөйгән ярым—
Син генә.
Бетмәс хәсрәт
Салып,
Мине ташлап ник китәсең?

Нигә мәхрүм итәсең?
Иркәләми,
Иркәләнми
Иреңә,
Җиде ятка
Барып,
Гомер буе хур итәсең.

Йөрәгем үртәнде,
Дөрләп янды,
Ялкын сарды
Эчемә.
Эттәй хурмын,
Зармын,
Өздеңлә син бу җилкәмне.

Кем белер иртәңне?
Әҗәл җиткәч,
Хәбәр итмәс
Кешегә,
Бүген әле
Бармын,
Юлдаш иттең син бүтәнне.

Гашыйклык кыен юл!
Җитсәң—җиттең,
Җитми үттең—

Ни булды?
Моңланып гомер
Үтте;
Уйлармы бер моны ул?

Алҗыды аяк кул,
Бетте хәлем,
Юк дәрманем,
Йөз сулды.
Соңгы көнем
Җитте,
Мин үләмен, син сау бул!

Чын йөрәк—кемне дә
Алдап йөрмәс,
Курку белмәс,
Юлыннан
Чигенеп кире
Каитмас;
Ант бозмас, күнәр үлемгә..

Хәлемне белергә
Килче, җаным,
Бер ал тагын
Кулымнан.
Һичкем сүз дә
Әйтмәс;
Рәхим кылсаң, кил күрергә!

Гашыйкмын мин һаман,
Көеп йөрсәм,
Сине күрсәм,
Ләм-мим дип
Бер сүз әйтер
Хәл юк;
Эреп китәмен шул заман.

Миңа син, багалмам,
Сер бүлмәдең,
Бер килмәдең
Күрим дип,
Эчеңдә эссе
Кан юк;
Хуш, таш йөрәк, бул аман!

Син гамьсез, күңелең тук.
Нурлы йөзең,
Җылы сүзең
Үземә
Язмагандыр
Алла.
Нишләргә соң, һич әмәл юк!

Аттың ник зәһәр ук?
Тәңре күрер,
Әҗрен бирер
Үзеңә,
„Сорамас“ дип
Калма:
Антын бозганны аяу юк!

1889

## ЕГЕТ СҮЗЕ

Сәламем ал, каләм каш,
Фида сиңа мал һәм баш,
Өзелеп сине сагынганда
Ага күздән кайнар яшь.

Синдәй сылу кыз тумас,
Туса сиңа тиң булмас.
Бер үзеңнән башкага
Яшь йөрәгем омтылмас.

Кайда гына йөрсәм дә,
Сүз бер булыр үлсәм дә,
Күңлем синнән аерылмас,
Күрмәсәм дә, күрсәм дә.

Ут үрләттең күңелгә,
Син күңлемнең түрендә,
Интизармын һәр заман
Нурлы йөзең күрергә.

Тәнең тәнгә тигәндә,
Онытылып сөйгәндә,
Бер чымырдап бер эрим
Эчем уттай көйгәндә.

Йөрәк янып йөргәндә,
Эч серләрем сөйләргә
Эзләп табар лачынмын, —
„Эзлә егет!“ дигәндә.

Холкың-фигъләң бик килгән,
Бер карап туйдым, димәм,
Сәгать саен көчлерәк
Тартылам сиңа нидән?

Күгәрченем, акканат,
Ач йөзеңне, бер карат,
Якынрак кил, алмабит,
Иркәлә, кайгым тарат!

1889

## КЫЗ СҮЗЕ

Килештереп мактыйсыз,
Нинди сүзләр тапмыйсыз,
Белсәң бездә ирек юк,
Әлләнигә башлыйсыз.

Без дә егет сайлыйбыз,
Һәр күргәнгә бармыйбыз,
Сездәй асыл очраса,
Җавапсыз да калмыйбыз.

Акылың үткер, сүзгә бай,
Сез янган ут, без бер май,
Кайнар сүзең керде эчкә,
Май торырмы чыжымай!

Кабул күрсәң—шат күңлем,
Ташлап китсәң, яшь гомрем
Әрәм булыр мәңгегә,
Зар елармын көн-төнен.

Теләгемне бирмәсәң,
Яхшы уйда йөрмәсәң,
Кысма мине куйнында,
Чыннан да дус күрмәсәң.

Кайгың булыр чиргә тиң,
Күңелем—кара җиргә тиң,
Синсез миңа тар түшәк,
Булыр салкын гүргә тиң.

Сез бер шонкар, ил даны,
Күп күргәнсез дөньяны,
Сезгә карый, сокланып,
Илнең чибәр кызлары.



446995

Әгәр йөрсәң күз салып,
Күңлең чыннан кузгалып.
Без күгәрчен, сез лачын,
Өзгәли бир, кил алып.

* * *

Моны яздым уйланып,
Уйларны җырга салып,
Ошатсагыз укырсыз,
Китапны кулга алып.

Кем дә укыса танып,
Йөрәгендә ут янып,
Дәрман булыр дәртенә,
Җырласа, көйгә салып.

Җырлар җыйган тырманып,
Көй өйрәнгән мырланып,
Мескен Күкбаи[1] хур булды,
Шундыйдан коры калып.

1889

---

[1] Күкбай—Абайның дусты, шәкерте, акын

## КӨЗ

Соры, салкын болытлар агылып тора,
Көз житсә, җирдә дымлы томан була.
Туйганымы, белмимен, туңганымы,
Уйнаклап тайлар берсен-берсе куа.

Чирәм дә, гөлләр дә юк далаларда,
Яшьләр көлми, уйнамый балалар да.
Теләнче карчыклардай төсе качып,
Агачлар бер яфраксыз калган бар да.

Кайберсе яңа тунга тире сайлый,
Ертык кием бер җылы бирә алмый.
Әбисеннән житәрлек җеп эрләтеп,
Яшь хатыннар иске киез өйне ямый.

Кыр казлары очалар көнгә табан,
Иген иккән илләргә бара кәрван.
Һичкайда уен-көлке ишетелми,
Авыллар һәммәсе дә тынып калган.

Бер-берсенә елыша бала-чага,
Карт-коры көч-хәл белән сулыш ала.
Өйдә сөяк булмагач, ачыккан эт
Кырларда тычкан аулап азык таба.

Йорт таралган, элекке ямь юк инде,
Җил чыкса, тузан баса бөтен җирне.
Сөрем тула өйгә, дип ут якмыйлар,
Казахта шул гадәт бер бетсен иде.

1889

* * *

Октябрь һәм ноябрь—бу ике ай
Китрә суык, башлана кыш та шулай.
„Иртә кайтсам, печәнем тиз бетә“ дип,
Малы белән җәйләүдә ятадыр бай.

Ярлы мескен мал карый иртә таңда,
Бигрәк салкын, утын да бетеп бара.
Яңа тунга тырышып тире или;
Чикмән тегә хатыны, калтырана.

Бала-чага өчен дә ямь калмаган,
Бөрешеп, утыралар өйдә һаман,
Шәфкатьсез суык үтә үзәкләргә, —
Карт-корының хәлләре бигрәк яман.

Куй суйган, бай өендә тәмле аш бар,
Кызыгып, ярлы читтән карый аңар,
Бирсә әгәр бер капчык кипкән тизәк,
Шуны да бай бик зур бер ярдәм санар.

Кар яуса да туңмыйдыр бай баласы,
Өе җылы, киез калын, әйбәт барсы.
Бай баласын уйната ярлы улы,
Үзе җылый, килә бит хәл аласы.

Аш бирмәс бай, кызганып, ярлыларга.
Бирсә әгәр эшләтеп җаның ала.
Байда шәфкать, ярлыда аң-белем юк,
Очраткан бит икесен бергә алла.

Күтәрелми күңеле, ярлы моңлы,
Байның да мактанырга бик юк урыны,
Картларны, балаларны ач үтермә,
Бер кыш сакла, таш булма, адәм хуры!

1889

* * *

Бай бик саран,
Холкы яман.
Илдә яхшы калмады.
Өлкән кеше —
Юк бер эше —
Илне хурлап алдады.

Юньле, юньсез,
Телле, телсез —
Һәммәсе дә бер йөри.
Сүксә түрә,
Булыс йөгрә
Өйдән өйгә, этмени!

Карыны бик тук,
Кадере һич юк,
Карамый үз халкына
Сүзгә күнми,
Эшли белми,
Ил таларга ашкына.

Чынны сөйгән,
Юньле йөргән
Күрмәдек бер эш ирен,
Кулга алып,
Бәла салып,
Ул каһәрле үз илен.

Чәчте малын,
Бирде барын
Менсен өчен урнына.
Инде талый
Армый-талмый,
Дөньяда тик ул гына.

Ил дә начар,
Ир дә начар, —
Инсафы юк бер кеше
Сыяз[1] житә,
Өяз[2] тетә,
Чыкмый барып бер эше.

Китте берлек,
Сүнде ирлек,
Хәсрәтеңне кем белер?
Ил талаша,
Тарткалаша,
Тайса аяк, кем күрер?

Үтте гомрем,
Бармый күңлем
Бу дөньяның эшенә,
Бергә йөреп,
Дус күренеп,
Алдый белгән кешегә.

Бәхете илнең,
Зарлы жирнең —
Булды бар жан атканың.
Бер һөнәрсез,
Дорфа, әрсез
Шушы йортмы тапканым?

1890

---

[1] Сыяз—съезд (волость башлыгын сайлау өчен).
[2] Өяз—өяз башлыгы мәгънәсендә.

* * *

Дөнья—салкын,
Гуя ялкын
Тулды кайгы гәүдәгә.
Серләшә алмыйм,
Сүз ача алмыйм
Бәндәгә.

Бер кабындым,
Бер ялындым,
Кемне күрсәм, мин аңар.
Әрнидер җан,
Дәрткә дәрман
Кем табар.

Йокы качкан,
Татлы аштан
Авыз итсәм, тәме юк.
Ял да белмим,
Дөньяның, дим,
Яме юк.

Сызлый йөрәк,
Яна дөрләп,
Бер тыныч җир кайда бар?
Үзең аң бул,
Тугры, ак юл
Сайлап ал!

Яшь тирәкнең яфрагы
Калтырыйдыр
Сукса җил,
Сулды гөлем,
Үтте гомрем,
Сынды бил.

Шат күңелле, —
Чая телле,—
Яши идем кайгысыз.
Хәстә—җаным,
Тирә-ягым —
Инде боз.

1890

* * *

Бүтәннән, күңелем, туярсың,
Җырны ничек куярсың?
Җырлаганда онытылып,
Бар кайгыңны җуярсың.

Сайра да моңлан, зарлы тел!
Тирән тойгы уянсын.
Җыласын, күздән яшь аксын,
Күкрәк яшькә чылансын!

Акылга сай, миңгерәү,
Шыр надан ни аңласын?
Күкрәгендә уты бар
Ир кеше гыйбрәт алсын!

Тыңламаса һич кеше,
Үз йөрәгем моңлансын,
Һәр сүзенә карасын,
Эчтәге дәрт кузгалсын!

Гөлләр булып аңкысын,
Ялкын булып балкысын!
Җылап, җырлап үлгәндә,
Яшь буынга сүз калсын!

Миндәй гарип очраса,
Колак салсын, уйлансын,
Кабул күрсә сүземне,
Кем таныса, шул алсын!

Файдасызга мең надан
Тыштан тыңлап калмасын,
Бер булса да, чын кеше
Эчке серен аңласын!

Сүз аңламый күп адәм,
Ничек мәгънә барласын?
Гыйлем дә юк, ми дә юк,
Белә тик уз даласын.

Йөрәк белән тыңламый,
Колак белән ни алсын?
Шуны күреп, аларга
Ничек итеп җырларсың?

1890

## ЯЗ

Язлар житсә, калмыйдыр кышның эзе,
Келәм төсле бизәлә җирнең йөзе.
Рәхәтләнә кешеләр, сайрар кошлар,
Үз анаңдай иркәли кояш безне.

Язны котлап, көньяктан кошлар килә,
Яшь-җилкенчәк кайгысыз уйный, көлә.
Гүрдән яңа torгандай карт-корылар
Һич тик ятмый, кыбырдый, үз эшен белә.

Утрак илләр күчмәгә аралаша,
Һәркем көлеп, күрешеп кочаклаша.
Дөнья куган яшьләрнең кулы бушап,
Чыр-чу килеп, серләшеп, күңел ача.

Бозау-бәти рәхәткә тиенгәннәр,
Күбәләкләр нинди бай киенгәннәр,
Борылып аккан сихерле саф суларга
Гөлчәчәкләр, агачлар иелгәннәр.

Казлар йөзә кыйгачлап якты күлдә,
Йомырка эзләп балалар армый бер дә;
Очкан атта йомырылып, лачын чөеп,
Бәхет сыный яшь егет язгы көндә.
Мул табышлы сонарчы кайткан чакта
Каршы чыгып, иркә кыз назлы көлә.

Язын көяз киенә яшь киленнәр,
Җир йөзенә ямь бирә асыл гөлләр,
Тугайларда сайраса былбыл кошлар,
Кәккүк куша таулардан моңлы көйләр.

Сәүдәгәрләр куана яңа малга,
Игенчеләр җир ерта, эштә бар да.
Мал-туарның берәве икәү булып,
Дәүләт арта, күңелле, рәхәт—җанга.

Бар җир йөзе бизәнгән шундый чибәр,
Миһырбанлык дөньяга нурын сибәр,
Җир-әнкәбез күкрәген имезгәндә,
Әткәң төсле, өстеңә күкләр инәр.

Яз җибәреп җан биргән кара җиргә,—
Рәхмәтенә тәңренең чик юк бер дә,
Мал симерә, куе сөт, аш күбәя,
Күтәрелә күңеле һәркемнең дә.

Кара таштан башканың барсы җанлы,
Бер саранннан башканың барсы җайлы.
Тикшереп бер карасаң бу эшләрне,
Бездәге байлыкларның чиге бармы?

Җылыналар кояшта карт-корылар,
Аунашалар чирәмдә яшь колыннар.
Кыйгак-кыйгак кычкыра күлдә казлар,
Кошлар сайрый, яңгырый киң болыннар.

Кояш юкта ай, йолдыз йөри бергә,
Кыен түгел ялтырау кара төндә;
Таң аткач кояш чыга, шуны белеп,
Бер почмакка ай поса әкрен генә.

Кояш—кияү, җир—килен, берсен-берсе
Шундый өзелеп сагынган һәр икесе.
Кияү килде, масаеп йөрү бетте,—
Ай, йолдызның бөтенләй качты төсе.

Ай, йолдызга җылы җил хәбәр бирде,
Җан иясе, куанып, туйга килде;
Сагышлы ак юрганын алып ташлап,
Җир яшәрде, аңар шат чырай керде.

Кияүне җир кыш буе көтеп ала,
Каушып булмый, бик ерак ике ара;
Киявенең сулышын тойганнан соң
Җир көлә, тутый коштай матурлана.

Күзне текәп кояшка булмый карап,
Тик нурында йөз аның, кайгың тарат;
Кызыл буйлы сары алтын чатырына
Кояшның кич кергәнен тордым карап.

1890

Күземнең карасы,
Бәгъремнең парәсы,
Һич китмәс йөрәктән
Гыйшкыңның ярасы.

Казахның данасы,
Күп күргән агасы:
— Була алмас синдәй,—ди,—
Адәмнең баласы.

Ничек соң түзәрмен,
Яшь түгә күзләрем.
Иркәмне мактарга
Чиксез күп сүзләрем.

Әдәптән узмамын,
Йөрәкнең сызлавын
Үзең дә беләсең,
Күп сөйләп сузмамын.

Бик текәп карыйсың,
Көлкегә саныймсың.
Сизмәмеш буласың,
Ник сынап армыйсың?

Син сабыр, чыдыйсың,
Көләсең, уйныйсың,
Көямен, янамын,
Һич рәхим кылмыйсың.

Акылсыз би булмас,
Шәүләсез өй булмас,
Йөрәге сап-салкын
Кешедә ми булмас.

Чын гыйшык соң булмас,
Соң булса сер булмас.
Зарымны әйтәмен,
Я булыр, я булмас.

Киң маңгай, калын сач,
Таралса, бер колач.
Ак муен, алма бит,
Җанкисәк, йөзең ач!

Каш кыйгач, күз кара,
Йөрәккә ут сала,
Авызың бал, кызыл гөл,
Үземә булсана!

Зифа буй, нечкә бил,
Сыгладыр, сукса җил;
Ачылган ал чәчәк,—
Килешле бөтен җир.

Кадерлем, кил бире,
Бер юат син мине!
Иркәләр иркәм дип,
Күп көттем бит инде.

Кайгың — кыш, йөзең — яз,
Көлсәң син — көн аяз.
Җырла бер яңгыратып,—
Былбылдай, — саф аваз.

Кил мине күрсәнә,
Бер назлап көлсәнә!
Аз сина, мал түгел,
Җанымны бирсәм дә.

Син тиңдәш саф гөлгә,
Балкыйсың шат көндә.
Миңа бер насыйпмы
Нурыңда эрергә?

Күңлемдә син генә,
Данлы син илемдә.
Һичбер тел чыга алмас
Мактауның чигенә.

Синсең — җан ләззәте,
Синсең — тән рәхәте.
Килешле яраткан —
Алланың рәхмәте.

Йөрәкнең янганы —
Гыйшкыңның фәрманы,
Елмаеп каравың —
Дәртемнең дәрманы.

Тез чүгә каршыңда
Гашыйклар барсы да.
Сүзләрем чуалган
Йөрәгем ярсуга.

Сиңа тиң кем чыгар?
Назыңа кем чыдар?
Ягымлы көлсәң бер,
Тәннәрем чымырдар.

Сихерләп һәркемне,
Тартасың күңелне.
Ходаем, бу йөрәк
Тынармы беркөнне?

1891

## Табышмак

Сигез батыр яраткан көчле тәңре,
Үзара сугышалар алар мәңге.
Бер егылып, бер торып тартышалар,
Кем җиңәсе билгесез һаман әле.
*Җавабы:*
Моны тапсам, уйланып, акын дигез,
Таба алмасам, акылы такыр, дигез.
Кыш белән яз, көн белән төн, так белән җеп,
Яхшылык һәм яманлык—булды сигез.

1890

Соргылт томан дым бөркеп,
Бәрхет бишмәт чылана.
Җиңе белән күз сөртеп,
Егет елыи, моңлана.
Кыз түгелсең, елама,
Тәвәккәл кыл ходага!
Җырла бер,
Өйгә кер.

Атаңны анаң аздырып,
Сөрдергән ич җәннәттән,
Тугры юлдан яздырып,
Мәхрүм иткән рәхәттән.
Тиз үзгәрә хатын-кыз,
Бүген ялкын, иртән — боз.
Билне бу,
Битне ю!

1892

* * *

Гыйшык теле — ул телсез тел.
Күз белән күр, күңелдән бел,
Сөешеп яшьләр хата итми,
Теләсәң син ышан я көл.

Ул тел таныш иде безгә,
Укый идек хәрефсез дә,
Укып яхшы аңлый идек,
Инде тынлык күңлебездә...

1894

* * *

Үзеңне зур дип уйлама,
Һөнәрле булып, алга бар.
Син дә бер кирпеч дөньяга,
Китеген табып, урын ал!

Иҗтиһат, акыл юл табар—
Качканга һәм куганга.
Гадәләт-шәфкать кемдә бар,
Шул сөйкемле—туганга.

Баштагы икәү соңгысыз
Була икән казахта:
Алдың — ялкын, артың — боз,
Барыр идең кай якка?

Файдаңны эзләп һәр җирдә,
Масаеп юкка мактанма.
Инсафлы кеше бул илдә,
Мәйданга чыкмый дан алма.

Һаман да күзгә ташланып,
Бүтәннән уза алмассың.
Көнчелек уче башланып,
Үзеңне утка салмасын.

Акрын йөреп, анык бас,
Хезмәтең китмәс далага:
Остазлык кылып ялыкмас
Галим кеше балага.

1894

* *

Ач кеше рәхәт таба, тамак туйса,
Тук кеше — алда әлван нигъмәт торса,
„Бер тую—ярты байлык“ дигән казах,
Күши бирә өзлексез, ите булса.

Хезмәт юк, хәрәкәт юк, казах ярлы,
Ач тору тинтерәткән тәмам аны.
„Иң яхшы аш ит белән кымыз“ диләр,
Юклыкны күрсәтмиме шул да тагы.

Ит, кымыз һәркемгә дә булса арзан,
Теләр идең тәмлерәк ашны һаман.
Үз-үзеңне туйдырыр хәлең дә юк,
Коллык кылып, ашыйсың ашы бардан.

Үз өеңдә туярга кулың кыска,
Аш бирер авыл эзләп йөрмә бушка.
Бер калҗа ит, бер савыт кымыз бирсә,
Шундук сине җибәрә бер йомышка.

Эшкә йөр, ят җиргә кит, мал табып кил,
Малың булса, сыйламый тора алмас ил.
Көч барында тырышып эшләмичә,
Бушка үткән гомерең — искән бер җил.

Тәвәккәлсез, хезмәтсез мал табылмас.
Эш сөймәгән ялкаулар адәм булмас.
Ишәк юып булса да мал табып кил,
Кулга йокмас, бирәү дә көлеп тормас.

Угрылык, алдау белән мал җыелмас,
Нәфсең шулай өйрәнсә, тиз тыелмас.
Зыян күрми калмассың андый эштән,
Мал китәр, мазаң китәр, абруй булмас.

Эшләмичә ашауга әй куана,
Дәүләтем бар дип уйлый ул дивана.
Хезмәт кылмый тапкан мал дәүләт түгел,
Нәкъ кар суы шикелле тиз югала.

Купшыланып, һәйбәтләп киенеп ала,
Ат менеп, сый эзләнә, һаман чаба.
Якты йөзен сата ул аш биргәнгә,
Андыйларның янына якын барма.

Оста ул юкны сөйләп көлдерергә,
Ярата эт шикелле тик йөрергә.
Үз өеннән җирәнеп читкә качкан
Тинтәкләргә кушылма гомереңдә.

1895

* * *

Балалык үтте, белдеңме?
Егетлеккә килдеңме?
Егетлек үтте, күрдеңме?
Картлыкка да күндеңме?

Кемнәр сөйләр хәлеңне,
Вәгъдә бозып йөрдеңме?
Вәгъдәледән көлдеңме?

Әллә инде, мескенем,
Тышаулы дөя шикелле
Абзардан чыкмый үлдеңме?

1895

* * *

Маллы дусның гаме юк малдан башка,
Чарасы юк һич аның алдамаска.
Табышына табынып, борын чөеп,
Бурыч бирә, тутыргач карынын башта.

Мал җыя ул, көчемне белдерәм, ди,
Күзгә төртеп мал белән көйдерәм, ди.
Үзе чучка, бүтәнне эт дип уйлый,
Шулпа биреп, ит биреп сөйдерәм, ди.

Мактамыйлар һичкемне бу заманда
Намусы, кешелеге, акылы барга.
Шакшыңны да ашарлар, бер сүз әйтми,
Эченнән аның алтын табылганда.

Моны укып, уйлан син, булсаң зирәк,
Хезмәт сат, намус сату нигә кирәк?
Өч нәрсә, адәмнең күрке дип бел:
Тырышлык, якты акыл, кайнар йөрәк.

1886

* * *

Күләгә озын сузылып,
Тау битләрен капласа,
Көн үз вакытын уздырып
Күк читеннән атласа,—

Гамьле күңелем уйлана,
Ерак китә уйларым,
Түбән карап моңлана,
Барлап гомер юлларын.

Үткән гомер—бер сукмак,
Кемнәр анда йөрмәде.
Кем алдады, кем тукмак
Булды, шәфкать белмәде.

Ни тапсаң да, тапканың
Ярамады кирәккә.
Шуны җыеп, кем тагын
Сибә зарлы йөрәккә?

Адашкан эт шикелле
Улап йортка кайткан уй,
Барыр юлың юк инде,
Юкны эзләп йөрмә, куй!

Әрем чыкты, хур итте,
Бодай чәчкән җиремә.
Дөнья куяр көн җитте,
Тыныч җан бир илеңдә.

1895

## АБДРАХМАН УЛЕМЕНӘ [1]

Егерме жиде яшендә
Абдрахман күз йомды.
Кайгы төште башыма,
Андый бала бер туды.

Дөнья колы булмады,
Борын чөеп йөрмәде.
Якын күрде туганны,
Хәйлә, ялган белмәде.

Гыйлем укып белмичә,
Һич тынычлык тапмады.
Дөнья гизеп күрмичә,
Рәхәт эзләп ятмады.

Озак гомер ни бирер,
Күргән-белгән булмаса.
Яткан надан ни белер,
Күңелгә нур тулмаса.

Петербурда торганда,
Белгән авыру алганын.
Зарланмаган шулай да,
Көткән тәнре фәрманын.

Уен-чыны аралаш,
„Гомрем аз“ дип белдергән.
Бүтән күздә күрсә яшь,
Шаярам, дип көлдергән.

Аз гомерен озайтты,
Белем булгач башында.
Гыйлем эзләп тәм тапты,
Өйрәнде ул барсын да.

---

[1] Абдрахман—Абайның улы. Төмәндә реальное училище бетереп, аннары Петербургта укыган. 1895 елда үлгән. Абдрахманга багышлап Абай күп кенә шигырь язган.

Рәсәй, Кырым һәм Себер,
Төркстаны калмады.
Үзе барып күрми бер,
Тынычлана алмады.

Койрыклы йолдыз шикелле,
Туды да күп тормады.
Күргән, белгән үкенде,
Ярдәм итеп булмады.

Тәвәккәл зур, акыл мул,
Шик йөртмәде күңлендә.
Тыныч үлә белде ул,
Сыкранмады беркемгә.

Ата-ананың хезмәтен,
Кемгә нәрсә бирәсен,
Үтәлмәгән хөрмәтен,
Язган — укып беләсен.

Күпне күреп, күп белгән,
Яше җиткәндәй йөзгә.
Эчтән янып тик йөргән,
Хәсрәт кылә дип безгә.

Яңа елның башы ул,
Мин искенең соңы идем.
Хәсрәт дигән ачы шул,
Үтте үзәккә минем.

Бөтен тәнем көйгәндәй,
Йөрәгемә ут капты,
Күзгә камчы тигәндәй,
Мөлдер-мөлдер яшь акты.

1895

* * *

Була шундый рәхәт чагың,
Эчтә кайгы басыла,
Шат сәгатьләр килә тагын,
Күк болыттан арчыла.

Саф чишмәдәй булса гомрем,
Чылтырап агар идем мин,
Бетмәсме дип күңел керем,
Юып карар идем мин.

Җан уяна, күз ачыла,
Таңнар ата, көн килә.
Гөрләвектәй сүз агыла,
Якты акыл көч бирә.

Шунда акын билне буып,
Тирә-якка күз сала,
Дөнья керен бетерә юып,
Уйга талып моңлана.

Лачын төсле үткер күзле,
Йөрәктә зар кузгала.
Наданлыкка үчле үзе,
Тыңлаган дулкынлана.

Гаделлеккә һәм акылга
Юрап күргән-белгәнен,
Җырлый ул ерак, якынга,
„Җырла шуны!“ дигәнен.

Дәртле йөрәк, саф күңел ул,
Изге теләк, ачы тел.
Нәрсә язса — дөресе шул,
Яратмасаң, үзең бел!

1895

* * *

Хан кулында яшәгән, ди, бер кыз бала,
Җан бирергә хәзер торган ханы аңа,
Киендергән атлас-ефәк киемнәргә,
Иркәләгән, имеш, сылу күңелен таба.

Шифа түгел яшь йөрәкнең ярсуына —
Матур кием, әлван нигъмәт, һичкайсы да.
„Карт сөйгәнче, корт ашасын тәнемне“ дип,
Кыз ташланган биек ярдан тирән суга.

Бизәк белән алдап булмый яшь күңелне,
Яшьләр сөйсә үзенә тиңне — шул күңелле,
Вакытың үтеп коры сөяк калганнан соң
Кыз баланы назлау тинтәклек түгелме?

Яшь йөрәкне алдый торган алтын булмас,
Карт белән яшь һич вакытта якын булмас,
Әгәр берәү утыз яшькә өлкән икән,
Акча биреп алган белән хатын булмас.

Тинтәк картлач матур бер яшь кызны ала,
Белдермичә кайгысын, кыз эчтән яна,
Икесенең арасында мәхәббәт юк,
Нишләсен соң, хайван түгел ул кыз бала.

Малга хирыс була кеше карт көнендә,
Карт гомерне мал яшәртә алмый бер дә,
Сылу кызны сатып алып бик күп малга,
Яшьлегеңне эзләвеңнән файда кемгә?

Бел, картлач бай, әгәр дә син гамьсез йөрсәң,
Мөгез чыгар, хатын әйткән сүзгә эрсәң,
Һич уңмассың, үз-үзеңә кәефләнеп,
Ашың белән хатыныңны мактап йөрсәң.

Бай үзенең карт хатынын тиргәп армый,
Яшь хатынның йөрәгенә җылы салмый.
Берсе — саф гөл, берсе — корып калган кура,
Кыш белән җәй мәңге бергә кушыла алмый.

Койрык болгап йөрүеңдә мәгънә бармы,
Күпме генә назласаң да яшь кызларны, —
Бер еллык юл — ике күңелнең арасы,
Картлач пәри ничек куша алсын аны.

1896

* * *

Кукрәп болыт килә дә,
Яңгыр ява кайчакта.
Башын түбән ия дә,
Зарлы елый аулакта.
Җылы яңгыр суыннан
Җир яшәреп, көч ала.
Бер еласаң, соңыннан
Баш авыртып, эч яна.

1896

## РӘХИМЧАЛГА[1]

Яхшы атның күрке — ял,
Ир кешенең күрке — мал,
Гомер сөргән адәмгә
Дәүләт—кызык, бала—бал.

Бал булырдай бала бар,
Бал булырмы Рәхимчал?
Болай биргән балаңны,
Биргән ходай, үзең ал!

18 6

---

[1] Бу шигырь Күҗәкбай дигән кешенең тәрбиясез, начар баласына каратып язылган.

* * *

Колактан кереп тарала
Яхшы җыр һәм матур көй,
Күңелгә төрле уй сала,
Җырны сөйсәң, миндәй сөй.

Дөнья калмый исемдә,—
Җырны шулай яратам,
Иртәсен дә, кичен дә
Җырлап кайгы таратам.

Сусаган, чүлдә су тапса,
Сусынын басмый калмый ул.
Берәү төртсә, я какса,
Туктап күз дә салмый ул.

Бер көйдереп, сөйдереп,
Яшь гомерне терелтә.
Гомер тунын кидереп,
Дәртләндереп йөгертә.

Ишеткәндәй буламын
Үткән заман моңнарын.
Тагын уйлап куямын
Гамьсез яшьлек чорларын.

Үткән көннең агуын
Тагын бер кат эчәмен.
Илнең юк-бар шау-шуын
Мактар хәлгә төшәмен.

Чынга алам, нечкәрәм,
Дөньяның бар ялганын.
Белмимен, мин эчмәгән
Нинди агу бар тагын?

1897

* * *

Үлсәм, миңа салкын гүр тыгыз булыр,
Үткер тел дә оялчан бер кыз булыр.
Мәхәббәт һәм дошманлык аралашкан,
Ялкын чәчкән йөрәгем тик боз булыр.

Тәкъдир язган көнем бер килеп җитәр,
Иртәме, соңмы тәндә дәрман бетәр.
Аягым чалыш баскан җирне табып,
Калганнар гайбәт сөйләр, гаеп итәр.

Шунда җавап бирә алмам мин бичара.
Акылың булса үзең бер уйлап кара:
Ике яну бер җанга гаделлекме?
Кара канлы адәммен, җанда—яра.

Йөрәк тавышын тыңларга син онытма,
Гомерем охшый дөрләп янган утка.
Сукмаксыз, чытырманлы җирдә үстем,
Меңгә каршы көрәштем, кинә тотма!

Яшьлегемдә ваемсыз, уйсыз үстем,
Хәйлә-мәкер, үч алу агуын эчтем.
Иртә уяндым, уйландым, җитә алмадым,
Илемнән җәфа күрер хәлгә төштем.

Бер карап, хәйран калам үз-үземә,
Юк-бар белән көн үткән, кермә эземә.
Ирек бирми, иярми ил хур итте,
Тыныч йоклат,—колак сал шул сүземә!

Эчемдә ачу тулган, тышым яна,
Инде китәм кайтмаска, нәрсә кала?
Серне шигырь гайбәтче илгә җәя,
Артык язма, җитәр дим, туктасана!

1898

* * *

Тутый коштай киенә,
Кунгач җире гөл генә,
Ләкин ничә көн генә
Күбәләкнең гомре дә.

Кешегә кирәк ни генә?
Кызыга ул киемгә,
Арлы-бирле йөгерә,
Эшли, сөя, сөелә.

Заман сөйри кемне дә,
Аны сөйрәр кем генә?
Хөкеме аның бер генә,
Барсын да или белә.

1902

* * *

Шатлык ул бер асыл таш, йөрәк — диңгез,
Шатлыксыз гомрең синең булмас тигез.
Йөрәктән кызу ялкын китә калса,
Тормышның бар кызыгы бетте, дигез.

Дус-дошманлык барсы да йөрәк эше,
Акыл ул — намусыңның күзәтчесе.
Көннән-көн мәртәбәсе арта барыр,
Намуслы һәм инсафлы булса кеше.

Картайгач, йөрәгеңдә ут аз кала,
Ут азайса, барыр юл тайгаклана.
Хәлең бетеп, аягың чалыш атлый,
Күргәннәр акыл биреп азаплана.

1902

* * *

Ат атландык
Туйга бардык,
Яхшы кием киенеп.
Күп җырладык,
Уйнап ардык,
Юкка-барга сөенеп.
        Сагыш-моң китте,
        Хур итте,
        Ни бетте?

Атабыз бар,
Бабабыз бар,
Әйгкәненә күнмәдек;
Ә соңыннан
Без шунар зар
Булабыз, дип белмәдек.
        Еракка качтык,
        Юл ачтык,
        Шаулаштык.

Язу яздык,
Хат таныдык,
Дәрес алдык мулладан.
Ул укудан
Нәрсә чыкты,
Һәммәбез лә чи надан.
        Каигысыз яшьлек—
        Юләрлек,
        Көләрлек.

Кызык таптык,
Кыз караттык,
Уен-көлке сөйләшеп.
Ат яраттык,
Дан тараттык,
Дуслар белән серләшеп.

Хәтергә килер,
Кем белер,
Кем күрер?
Алга бардык,
Хатын алдык,
Үсте бераз аңыбыз.
Тормыш кордык,
Төпле булдык,
Үтте юләр чагыбыз.
Үткәнең кайда?
Абайла!
Ни файда?

1902

# ПОЭМАЛАР

## МӘСГУТЬ

Я алла, хөрмәтендә дустың Мәхмүд,
Телгә көч бир, беленсен безнең максут.
Яшәгән Һарун Рәшид заманында
Багдадта бер яшь егет, исме Мәсгуть.

Шәһәрдән беркөн Мәсгуть чыккан иде,
Коточкыч начар хәлгә туры килде:
Бер угры ак сакаллы картны талый,
Яшь егет шуны күреп түзәрме инде.

Бичара карт кычкыра хәлдән таеп,
Аерып алыр кеше юк, аны барып.
Кем булса да бер ирлек кылыйм диде,
Мәсгуть китте кулына хәнҗәр алып.

Явыз угры уйната үткер кылыч,
Йөкләде Мәсгуть өскә изге бурыч,
Җиңде ул, качып китте угры бик тиз,
Картыбыз исән калды, юк куркыныч.

Шатланып, Мәсгутькә карт йөгереп бара,
Күрә, аның башыннан каны ага.
—„Саф күңелле, намуслы, батыр егет!
Миннән моның әҗерен алмый калма!“

—„Әй егет, ни кылсаң да ир икәнсең,
Ирлектә илегездә бер икәнсең,
Сәбәп булып әҗәлдән алып калдың,
Рәхмәткә лаек кеше син икәнсең.

Бай түгел, батыр түгел, хан түгелмен,
Атаклы, илдә данлы карт түгелмен,
Сәбәп булып аердың мине әҗәлдән,
Яхшылык кадрен белмәс зат түгелмен.

Мин бер картмын, дөньяны бик күп гизгән,
Иртән төштә китәмен шәһәрегездән,
Иртәрәк фәлән җиргә килеп чык син,
Бер бүләк алсаң кирәк шунда бездән.

Акчага кызыкмассың син батыр ир,
Миңа сине очраткан тәңре дип бел,
Сорыймын бер ходаның хакы өчен,
Сүземне кабул кылып, кулыңны бир!"

Иртүк Мәсгуть күрсәтелгән җиргә барды,
Әлеге карт аны шунда каршы алды,
Кулыннан кысып тотып, егетне ул
Ташландык бер кабергә алып барды.

Барса, анда үсә бер сахра гөле,
Ул гөлнең җимешләре төрле-төрле:
Берсе ак, берсе кызыл, берсе сары,
Сайласын — кайсын тели егет күңле.

„Аклың артыр, ашасаң әгәр агын,
Сарысын алсаң, чиксез булыр малың,
Кызыл җимеш ашасаң, хатын-кызлар
Сине сөяр—ниндине тели җаның".

Ул егет карт сүзенә колак салды,
Күзен түбән текәде, уйга калды,
Акны да, сарыны да алмыйм, диде,
Бирегез кызыл җимеш дип сорады.

—„Әйткән сүзем каладыр әйткән көйгә,
Бирәмен, тик соңыннан үкенеп йөрмә,
Акны да, сарыны да алмавыңның
Мәгънәсен, батыр егет, миңа сөйлә!"

—„Әгәр мин ак җимешне алса идем,
Аклым белән аерылам илдән, дидем,
Акылга хуҗа булмам ни кылсам да,
Үземә акылым хуҗа булыр минем.

Акыллы җан табылмас миңа сердәш,
Тинтәкләр һәм наданнар кадрем белмәс,
Акылсыз, гадәләтсез, әрсезләрне
Күреп тору күңелгә тынгы бирмәс.

Адәм авыру буладыр, хәсрәт артып,
Татлы йокы иокламый төнлә ятып,
Тилегә, теләсә дә, им табылмый,
Ләззәт тапмый тәгамның тәмен татып.

Булсам, ашап сарыны, баиның үзе,
Минем турыда булыр тик халык сүзе.
Берәр нәрсә бу баидан алсак ла дип,
Текәлер һәммәсенең миңа күзе.

Көнләрләр илдән артык байлык өчен,
Берсе сатар намусын, берсе—көчен.
Наданнар ни булса да алу уйлар,
Шул нәләт мал көйдерер илнең эчен.

Эшләмичә мал җыю—хәерчелек,
Акыллы ирләр өчен зур кимчелек.
Бу көндә аны уйлар кеше бармы,
Дус булганчы файдасын уйлый элек.

Бирсәң әгәр, адәмнең кадрен алдың,
Бирмәсәң, яман бер эт булып калдың,
Үзең эт, илең-йортың һәммәсе эт,
Котылмас бер бәлагә кереп тардың.

Кызыл җимеш ашасам, хатын сөяр,
Бозыклыкта иөрмәсәм, кемнәр көяр,
Хатын-кыз бик күп алар, дус булсалар,
Уйлыймын, бер файдасы бәлкем тияр.

Ир кешегә ир кеше дошман булса,
Хатыны, кызы шуны күреп торса,
Арадаш булалар бит шунда алар,
Хан каһәрләп, кайберәү хаслык кылса.

Хәстәрсез адәм башы һич сау булмас,
Өеңдә тикшерелмәс бер дау булмас,
Ачулы ирен хатын татулыкка
Өндәп торса, кычкырыш-җәнҗал тумас.

Сайладым кызыл җимеш, уйлап шуны,
Теләгемне яшерми әйтәм туры,
Бирсәгез, рәхмәт әйтеп алачакмын,
Баштан ук уйладым мин ныклап моны*.

Карт аңар шул сүзләрне әйтте тагын:
—„Бик дөрес җавап бирдең,—ал, чырагым,
Акыл, дәүләт электән үзеңдә бар,
Гомерең буе бәхетең артсын, җаным!“

Бу карт бүтән карт түгел, Хозыр иде,
Егетнең бәхетенә туры килде.
Аның фигълен, акылын, әйткән сүзен
Яратып, „фатихамны бирәм“ диде.

Мәсгуть шулай Хозырдан дога алган,
Соңыннан Шәмсе-Җиһан дип аталган.
Мәгънәсе: „Шушы дөньяның кояшы“,
Хикәя безгә гыйбрәт булып калган.

Ул чакта да наданнар эшне бозган,
Тормыш ямен тапмыйча гомер узган,
Акылны да, малны да тота белми,
Эзләгәннәр ярдәмне хатын-кыздан.

Хәзерге заман хәле бигрәк яман,
Адәмдә акыл, намус, әр калмаган.
Тормас идем шушында, җибәрмидер
Туган туфрак, гүрдәге ата-бабам.

Шул Мәсгуть хәлифәгә вәзир булган,
Халык аны хөрмәтләп, зурлап торган.
Бер тын кичне йокыга талгач Мәсгуть,
Хозыр карт килгән аңар, әйткән шуннан:

— „Әй балам, фәлән көнне яңгыр явар,
Ул яңгырның суында кәсафәт бар,
Җиде көн җенле булыр су эчкәннәр,
Җиде көн үткәннән соң терелер алар.

Ярларыннан ташарлар бар елгалар,
Җенле су зур бер ташкын булып агар,
Онытма, таза судан су җыеп ал,
Бу хәбәрем, саклансаң, сиңа ярар“.

Шунда ук хәлифәгә Мәсгуть барды,
Хәлифә мәсьәләне тиз аңлады.
Әйткән көн якынлашып килгән чакта
Таза судан җитәрлек коеп алды.

Вәгъдәле көн бер килде, яңгыр яуды,
Су эчкәннәр женләнде, шашты бары,
Көне-төне шаулашып талаштылар,
Ашау-эчү онытылды, йокы калды.

Алар шаулап беркөнне килде ханга,
Хан һәм вәзир карыйлар тамашага,
Һәммәсе, акылын җуеп, җенле булган,
Шаулаша бала-чага, өлкән ага.

Халыкның янына хан якын барды,
Аңлатырга тырышты, акыл салды.
—„Агайлар, бер авыруга юлыккансыз,
Өйгә кайтып йоклагыз"—дип чыгарды.

Киттеләр алар ханга ачуланып,
Урамнарда йөрделәр сөрән салып.
— „Хан һәм вәзир акылдан язганнар ич,
Үтерик һәр икесен,—диләр,—барып".

Бар җенлеләр сарайга кире килде,
Хәлифә дә аларның уен белде,
Аның хәле элеккедән мөшкелләште,
—„Вәзир, тизрәк акыл тап, нишлик?"—диде.

—„Чара юк котылырга һич тә моннан,
Без дә эчик, булмаса, җенле судан.
Җенлеләр тели безне үтерергә,
Уйлыйлар, имештер, без җенле булган".

Икесе җенле судан эчеп алды,
Котырып халык каршысына барды.
Бөтен җенле „ялгышып әйткәнбез" дип,
Коллык кылып, боларга күп ялварды.

Шуннан соң һәммәсе дә кайтып китте,
Кыскасы, таралырга вакыт житте.
Күрдеңме, күп тинтәкнең кылган эшен
Акыллыны ирексез тиле итте.

Гыйбрәтле бер мисал бу—әгәр белсәң;
Күп кеше әйтә бит дип кабул күрсәң,
Гафил син, күп нәрсәдән буш калырсың,
Аңламый кеше сүзе белән йөрсәң.

1887

## ИСКӘНДӘР

Укучым Искәндәрне беләмикән?
Македония илендә туган икән,
Филипп патша баласы, батыр җанлы,
Мактау сөйгән, тәкәббер адәм икән.

Филипп үлде, Искәндәр патша булды,
Яше аның егерме бергә тулды.
Үз иле аз күренеп, күршеләргә
Күз алартып карады уңлы-суллы.

Гаскәр җыеп, явыз эш ният кылды,
Якын җиргә яу булып ябырылды.
Күп илне көтмәгәндә вәйран итте,
Ханны үтереп, халкының барсын кырды.

Җәзасыз кан түгүдән кызык тапты,
Дәрьяларның суыдай каннар акты,
Барган илнең барсын да буйсындырып,
Халыкларын михнәткә, утка атты.

Искәндәр жиңә алмаган хан булмады,
Җиңгән саен күңеле һич туймады.
Комсызлык барган саен арта төште,
Җир йөзен басып алыйм, дип уйлады.

Кан эчкеч, мәрхәмәтсез, каһәрле хан,
Тирә-як тетрәп, куркып торган аннан.
„Ханнар ханы, патшалар патшасы!“ дип
Каршында ялагайлар йөргән һаман.

Даны аның иң ерак илгә җитте,
Инсаф, оят һәммәсе тәмам бетте.
Хисапсыз гаскәр алып, хәстәрләнеп,
Ишеткән илләренә чыгып китте.

Алдыннан чыга алмады һичкем аның,
Калдырмады һичберсен очраганның.

Туктаусыз алга барды, кыра-жимрә,
Хуҗасы булам, диде, бар дөньяның.

Бара-бара, очрады бер сахрага,
Тамчы да су табар хәл һич юк анда,
Алып килгән суының барын эчте,
Төкәнмәс кайгы салды ходай җанга.

Хайван, адәм, барысы да сусап калды,
Нишләргә белмәде ул аптырады,
Хезмәткәрнең барсын үтермәкче булды,
Җиткерде сусыз калу шуңар аны.

Астындагы тулпары алга очты,
Искәндәр дә ныклап аның ялын кочты.
Ялтырап шәүлә биргән бер нәрсәгә
Шул чагында патшаның күзе төште.

Барса, күрә: чылтырап саф су ага,
Тасмадай сузылып киткән еракларга.
Җиргә ятып Искәндәр башын куйды,
Татлы су, эчтең исә—шифа җанга.

Сорады патша: кипкән балык бармы?
Балыкны агар суга салып алды.
Исе, тәме башкача булып китте,
Моны күреп һәммәсе хәйран калды.

Искәндәр әйтте шунда: „бу нинди су,
Барың эчеп, шул суда битеңне ю,
Бер бай илдән мондый су чыкса чыгар,
Киттек тизрәк! Өстенә кадарбыз ту[1].

Шул татлы, салкын судан кансын сусын,
Миңа каршы торыр җан кайда тусын,
Су буйлап туктамастан йөрик алга,
Бай шәһәр тезен чүксен, безгә булсын!“

Су буйлап төннәр-көннәр гаскәр барды,
Туктатучы булмады юлда аны.
Җиңү артлы җиңүне күргән батыр
Жыр җырлап, уйнап-көлеп, сөрнай чалды.

[1] Ту — байрак, әләм.

Бара торгач, җиттеләр бер зур тауга,
Су башы икән әнә шул тауларда,
Ике тау арасында алтын койма,
Капка бикле, үтәргә юл юк анда.

Капканы ачарга дип хан омтылды,
Тоткасын алай борды, болай борды,
Ача алмады, капкадан өмет өзде,
Аптырап, бераз вакыт басып торды.

Искәндәр күпме җирләр сугышып алган,
Һичкайчан туктау күрми алга барган,
Алдында тез чүккәннәр күпме илләр,
Патшалар тетрәп-куркып торган аннан.

Дәһшәтле Искәндәр хан ачуланды,
Ачуланып, капкага тагын барды,
Капканы дөбердәтеп кага-кага,
Ачарга әмер биреп, мазаланды.

Капканың аръягыннан берәү килде,
Күзәтчесе шул икән, тавыш бирде,
—„Капканы сиңа ачарга рөхсәт юктыр,
Бу — ходайга илтүче капка“,— диде.

—„Белмәсәң, мин Искәндәр патша үзем,
Сугышта җиңгән ханмын бар җир йөзен,
Туып-үсеп күрмәдем мондый хурлык,
Тизрәк капкаңны ач, кыска сүзем!“

—„Акыл белсәң, батыр дип мактанма син,
Батыр булсаң, үзеңнең нәфсеңне җиң.
Кара эчле мактанчык, көнче адәм,
Андый кеше бу җиргә була алмас тиң“.

—„Дөньяны буйсындырган мин дә бер ир,
Күп күрдем, туры килде күрмәгән җир,
Һич булмаса, халкыма күрсәтергә,
Бүләк дип, билге булыр бернәрсә бир!“

Койма аша бер төен ташладылар,
„Бүләк шушы, падишаһ, кулыңа ал!
Эчендә бернәрсә бар, акыл бирер,
Гыйбрәт булыр—уйланып күзеңне сал!“

Искәндәр бик куанып, төенне алды,
„Бүләк бар!“ дип халкына хәбәр салды.
Караса, эчендә бер коры сөяк,
„Бу нинди мыскыллау!“ дип таңга калды.

Чамасыз ачуланды һәм гарьләнде,
Ничек тә аңламады мондый хәлне,
„Булмаса, бүләк бирә дә белми“ дип,
Сөякне бик еракка атып бәрде.

Юлдашы Аристотель, акылы мул,
Атып бәргән сөякне алды да ул,
Ханга әйтте: „Бу сөяк хасиятьле,
Күзең белән күреп син хәбәрдар бул!“

Искәндәр: „Сөйлә, тыңлыйм“ диде аңа,
Чын киңәшне тотмыйча бармы чара.
—„Бер ягына үлчәүнең сөякне сал,
Бер ягына алтын сал, — үлчәп кара!“

Китерделәр зур үлчәү киң мәйданга,
Карарга дип җыелды гаскәр анда.
Бер кечкенә сөякне баса алмады,
Күпме алтын-көмешне салсалар да.

Моны күреп, Искәндәр хәйран калды,
Алтынга коралларын өстәп салды.
„Инде нишләр икән?“ дип карасалар,
Коры сөяк тагын да авырланды.

Аристотель хәкимгә патша килде:
—„Коры сөяк казнамның барын җиңде,
Бу сөякне басарлык нәрсә бармы?
Акыл белән тикшереп тапчы“ — диде.

Хәким җирдән тик бер уч туфрак алды,
Үлчәүдәге сөяккә сипте аны.
Алтын ягы шунда ук түбән төшеп,
Сөяк ягы югары менеп калды.

Искәндәр моны күреп аптырады,
Хәкимне аулак җиргә алып барды,
„Таң калырлык гаҗаип эш булды бу,
Мәгънәсен аңлатып бир!“ дип сорады.

— Бу — адәмнең күз сөяге, — диде ханга, —
Туймыйдыр күз алтынга һичкайчан да,
Комсыз күз җир йөзендә туймаса да,
Үлсә туя, бер уч туфрак коелганда.

Туймас күзнең дөньяда нәфесе зур,
Алган саен алырга омтыла ул,
Тере чакта чик белми, әмма, үлгәч,
Башкалардан артыклык һич калмый шул.

Ачуланма, и патшам, аңлау кирәк:
Буләк, дидең, биргәне коры сөяк,
Бирмәде сезгә рөхсәт алтын капка,
Моны күреп, алыгыз сез дә гыйбрәт!"

Искәндәр шунда тирән уйга талды:
„Бу эшемнән миңа бер мәгънә бармы?
Ходаем үзе барысын аңлатты!" дип
Үз иленә кайтадан китеп барды.

Хикәям шунда тәмам булды, син дә,
Укып чыккач, моны бер буш сүз димә,
Карының туйса, кайгырма даным юк дип,
Туймас күзең тулыр дип хәсрәт чикмә.

Берәү дә мәңге тормый, гомрең үтәр,
Үз-үзеңнән көлдереп, йөрмә, җитәр,
Оят белән намусны малга сатма,
Оятсызда иман да калмас, бетәр.

Мактанасың берәүгә, „мактасын!" дип,
„Һичкем дә гайбәтемне сатмасын!" дип,
Үзең киткәч, артыңнан көлеп кала,
„Бу тинтәктән ходаем сакласын!" дип.

Акылсыз үзен мактап кәеф таба,
Аңламый үз чамасын ул бичара,
Үз бәһаңне үзеңнән сорамыйлар,
„Мин бик шәп!" дип, лаф орып бармы файда?

1901

## ЭЧТӘЛЕК


**Сүз башы** *Бит*

**М. Максуд** Казах халкының бөек улы . . . . . . . . . . . 3

ШИГЫРЬЛӘР

Карлар яуса, бөркетче чыга ауга . . . . . . . . . . . . . . . 7
Ягымлы, ак чырайлы, киң маңгайлы . . . . . . . . . . 9
Картайдык, хәсрәт басты, йокы сирәк . . . . . . . . . . . 10
Ярлы халкым, казахым, вәйран илем . . . . . . . . . . . 12
Егетләр, уен арзан, көлке кыйбат . . . . . . . . . . . . . 13
Гыйлем тапмый мактанма . . . . . . . . . . . . . . . 16
Җәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Шигырь—сүзнең патшасы, сайланмасы . . . . . . . . . . 20
Кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Сигезаяк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Шигырь язмыйм бер кызык күрмәк өчен . . . . . . . . . 28
Син мине нишләтәсең . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Егет сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Кыз сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Моны яздым уйланып . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Күз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Октябрь һәм ноябрь—бу ике ай . . . . . . . . . . . . 36
Бай бик саран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Дөнья—салкын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Бүтәннән, күңелем, туярсың . . . . . . . . . . . . . 40
Яз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Күземнең карасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Табышмак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Соргылт томан дым бөркеп . . . . . . . . . . . . . . 47
Гыйшык теле—ул телсез тел . . . . . . . . . . . . . . —
Үзеңне зур дип уйлама . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Ач кеше рәхәт таба, тамак туйса . . . . . . . . . . . 49

Бит

Балалык утте, белденме . . . . . 51
Маллы дусның гаме юк малдан башка . . . . —
Күләгә озын сузылып . . . . . 52
Абдрахман үлеменә . . . . . 53
Була шундый рәхәт чагың . . . . . 55
Хан кулында яшәгән, ди, бер кыз бала . . . . . 56
Күкрәп болыт килә дә . . . . . 58
Рәхимчалга . . . . . —
Колактан кереп тарала . . . . . 59
Үлсәм, миңа салкын гүр тыгыз булыр . . . . . 60
Тутый коштай киенә . . . . . 61
Шатлык ул бер асыл таш, йөрәк—диңгез . . . . . —
Ат атландык . . . . . 62

ПОЭМАЛАР

Мәсгуть . . . . . 64
Искәндәр . . . . . 69

Г 466945

Қазақстан
Ұлттық кітапханасы
2 100114 396711

4 100689 4 267094 100689 4 2670

АБАЙ

СТИХИ

(на татарском языке)

Җаваплы редакторы *Кави Нәҗми*

Техник редакторы *Г. Гобәйди*

Корректоры *З. Шагдалеева*

ПФ 09131—18/III-1947 Заказ № 012 Тиражы 5000

**Издательстволар һәм полиграфия идарәсе янындагы Татполиграф типографиясе. Казан, Миславский ур., 9.**